ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Новая, д.52, с. Старое Чурилино,
Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске
Чүриле авылы, Арча муниципаль районы,
422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

КАРАР

**23 декабрь 2022 ел** **№ 23**

**Арча муниципаль районы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 4 августындагы 49 номерлы Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карары нигезендә, җыеннарда кабул ителгән 15.11.2022, №1, 15.11.2022 № 2, 16.11.2022 № 3, 19.11.2022 № 4, 20.11.2022 № 5, 20.11.2022 № 6, 25.11.2022 № 7 карарларны тормышка ашыру максатыннан карарларны тормышка ашыру максатыннан Иске Чүриле авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Арча муниципаль районы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Арча районы Иске Чүриле авылы, Яңа ур., 52; Татарстан Республикасы, Арча районы Венета авылы, Үзәк урамы, 13 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы Ашабаш авылы, Комсомольская урамы, 4А йорты; Татарстан Республикасы, Арча районы Штерә авылы, Совет урамы, 30б.

3. «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында» Иске Чүриле авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 24 декабрендәге 22 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы                Р.Т. Хидиятуллин

Иске Чүриле авыл җирлеге
башкарма комитетының
23.12.2022 ел, № 23
карарына 1 нче кушымта

**Арча муниципаль районы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Арча муниципаль районы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү Арча муниципаль районы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан алар тавыш биргәндә чагылдырган мөнәсәбәтләренә һәм җыеннарда катнашуларына бәйсез рәвештә 2023 елның 19 февраленә кадәр башкарыла.

3.Түбәндәге категория гражданнар үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) махсус хәрби операциядә катнашучылар (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән хәрби хезмәткә киткән затлар) һәм аларның гаилә әгъзалары (бергә яшәүче ата-аналары, ире яки хатыны, балигъ булган балалары)

4. Гражданнарның аерым категорияләре:

а) көндезге уку формасы буенча укучы студентлар,

б) 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнар,

в) хәрби хәрәкәтләр,

өчен түләү күләме җирле җыеннар карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

5. Түбәндәге нигезле сәбәпләр булганда:

а) гаилә әгъзасының үлеме (ата-анасы, хатыны/ире, балалары),

б) янгын яки башка табигый бәла-казалар нәтиҗәсендә зыян күрү,

гражданнарга гариза нигезендә өч айдан да артмаган вакытка түләү кертүне кичектереп тору каралган булырга мөмкин.

6. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында хәбәр (хәбәрнамә) бланкы (http://pravo.tatarstan.ru) сайтында һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында ( http://arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру, шулай ук кул куйдырып тапшыру яисә почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән халыкка җиткерелә.

Хәбәрдә (хәбәрнамәдә) гражданнарның үзара салым акчаларын кертү өчен түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

7. Гражданнарның үзара салым кертүләреннән җыелган акчалар Арча муниципаль районы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

8. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукы булган оешмалар, почта күчерүләре (исәп-хисап оешмалары) яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru сылтамасы буенча күчерү юлы белән башкарыла.

9. Түләү фактын раслау - касса ордеры квитанциясе, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслый торган башка документлар.

10. Билгеләнгән срокта кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Иске Чүриле авыл җирлеге
башкарма комитетының
23.12.2022 ел, № 23
карарына 2 нче кушымта

«Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләү турында

ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № ____

Түләүченең Ф.И.А.и. ______________________________
Адресы:_____________________________________________________________
Сезгә ________________________________________________________нигезендә чараларны гамәлгә ашыруга ______ сумлык бер тапкыр түләнә торган түләүне түбәндәге реквизитлар буенча ________________________________ кадәр түләргә кирәк:

БИК банк ______________________________
Сч. № _________________________________________
Счетны алучы № _________________________________
ИНН _______________________________________________
КПП _______________________________________________
КБК __________________ОКАТО___________________
Түләүнең билгеләнеше
______________________________________________________________________________

Җитәкче ___________________ ___________________________________________
(имза) ( имзаның аңлатмасы)

М. у.

кисү сызыгы- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

«Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына ___________ сум күләмендә үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләүне кертү турында хәбәр (хәбәрнамә) № ___
Түләүченең Ф.И.А.и. _______________________________________________________
Адресы: ___________________________________________________________
Алдым "___" ______________________ел _____________________________
(имза/түләүченең ф.и.а.и.)

*Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән бирелгән очракта, өзмә корешок тутырыла һәм Иске Чүриле авыл җирлеге башкарма комитетында кала.*